## III.3. СҮЗЛЕКНЕ КУЛЛАНУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ТУРЫНДА

Дүрттелле тематик сүзлектән рус, татар, инглиз һәм төрек телләрен өйрәнүчеләр дә, әлеге телләрне укытучылар да төрлечә файдалана ала. Сүзлекне кулланып әзерләргә яки үтәргә мөмкин булган кайбер төр биремнәрне күрсәтеп үтик:

әлеге тематик төркемгә кергән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне ачыкларга;

тематик төркемгә кертелгән сүзләрне кулланып, сүзлектә бирелгән төрдәге яки башка төрдәге яңа сүзтезмәләр төзергә;

сүзлектә китерелгән сүзтезмәләр белән җөмләләр төзергә;

мөстәкыйль рәвештә төзелгән сүзтезмәләрне яисә җөмләләрне башка телгә тәрҗемә итәргә;

сүзлектә китерелгән җөмләне кулланырга мөмкин булган ситуацияне тасвирларга;

сүзлектә тәкъдим ителгән җөмләләрне кулланып, диалог төзергә;

тематик төркемдә китерелгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне кулланып, бәйләнешле текст төзергә;

тематик төркемдә бердән күбрәк мәгънәгә ия булган сүзләрне табарга. Мисалларда аларның күпмәгънәлелеген күрсәтергә;

тематик төркемдәге род-вид мөнәсәбәтләре белән бәйле сүзләрне табарга (гомуми төшенчә, шәхси төшенчәләр). Әлеге сүзләр белән мисаллар китерергә;

тематик төркемгә кергән (куллану лексикасы составыннан) кайбер сүзләргә аңлатма бирергә;

иң еш кулланыла торган берничә сүз өчен барлык мөмкин булган тамырдаш сүзләрне табарга;

тематик төркемдәге тамырдаш сүзләрне табарга, мәгънәләренең аермасын мисалларда күрсәтергә, шулай ук әлеге сүзләрне төзелеше ягыннан яисә сүз ясалышы буенча тикшерергә;

тематик төркемдә төзелеше ягыннан охшаш тамырдаш булмаган сүзләрне табарга, әлеге сүзләрне сүз ясалышы ягыннан тикшерергә;

тематик төркемдә китерелгән сүзләрнең грамматик үзенчәлекләре белән танышырга (мәсәлән, инглиз телендә дөрес булмаган фигыльләр). Әлеге үзенчәлекләрнең чагылышын мисалларда күрсәтергә. Шундый ук үзенчәлеккә ия башка сүзләр табарга;

тематик төркемгә кергән билгеле бер сүз төркеменә караган сүзләрнең теге яки бу формасын ясарга (мәсәлән, рус өлешендә – фигыльнең 3 зат берлек сан формасын, исем өчен иялек килешендәге берлек сан формасын һ.б.);

сүзтезмәләр һәм җөмләләр составына кергән сүзләргә морфологик анализ ясарга.